Рәхмәт хаты

Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре
мәгариф идарәсенең укыту-методик яктан
тәэмин итү бүлеге методисты
Р.Р.Исмәгыйлевага

Хөрмәтле Резедә Рәиф кызы!

Күп еллар дәвамында Түбән Кама районы һәм шәһәрендәге талантлы балалар арасында иҗади бәйге үткәрелә. Бәйгедә җиңеп чыккан укучыларның күбесе хәзерге көндә югары уку йортларында белем ала. Аларның кайберләре инде укуларын тәмамлап, туган якларына кайтып эшлиләр дә.

Балаларның фикерләү сәләтен, иҗади активлыгын формалаштыру һәм үстерүгә шартлар тудыруыгыз өчен Сезгә олы рәхмәтемне белдерәм.

Киләчәктә дә халкыбызның телен, рухи кыйммәтләрен, йолаларын саклап, инде матур традициягә әверелгән бу бәйгене оештыру һәм үткәрүдә бергәләшеп эшләрбез дип ышанам.



Татарстанның халык шагыйре,
Дәүләт Советы депутаты *РАЗИЛ ВӘЛИЕВ*

2015 ел, май